КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 ноябрь г.Казань № 984

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 3 нче; 2015 ел, 12 февраль, 85 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 706 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктта:

икенче абзацка «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә» сүзләреннән соң «(җирлек, шәһәр округы составына керүче торак пунктта)» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацка «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә» сүзләреннән соң «(җирлек, шәһәр округы составына керүче торак пунктта)» сүзләрен өстәргә;

11 пунктка «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә» сүзләреннән соң «(җирлек, шәһәр округы составына керүче торак пунктта)» сүзләрен өстәргә;

1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 9 ноябрь, 984 нче
карары редакциясендә)

Форма

Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә
заявка

____________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме, җирлек, шәһәр округы составына керүче торак пункт)

____________________________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләсе исеме)

| Т/с | Чаралар исемлеге | Чараларны тормышка ашыруга акча, мең сум | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | кабат кабул ителгән карар буенча җәлеп ителгән гражданнар акчасы | бюджетара трансфертлар бирелмәгән элек кабул ителгән карарлар буенча җәлеп ителгән гражданнар акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Барлыгы | | | | | |

Муниципаль район, _____________/_______________________/
шәһәр округы башлыгы (имза) (имзаның аңлатмасы)
М.У.

____________________________________________